| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ПИСЬМЯНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ПИСМӘН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ                Подлесный                КАРАР

08.02.2024                                                № 3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 19 декабрендәге 26 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 19 декабрендәге 613-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 19 декабрендәге 26 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәреш кертергә:

42 нче маддәнең 2.3 нче өлешендәге 5 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«зиратларны, терлекләр каберлекләрен, җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру объектларын, химик, шартлаткыч, токсик, агулы матдәләрне (исемлекләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган диңгез портлары территорияләрендәге аммиак, метанол, аммиак селитрасы һәм калий нитраты махсус саклагычларын исәпкә алмаганда, яр буе саклау полосалары чикләреннән тыш), радиоактив калдыкларны күмү пунктларын урнаштыру, шулай ук территорияне, балык хуҗалыгы әһәмиятендәге су объектларында рөхсәт ителгән чик концентрацияләре билгеләнмәгән территорияне пычратучы матдәләр белән пычрату;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Подлесный поселогы, Гагарин урамы, 5 йорт; Иске Писмән авылы,Үзәк урам, 50 йорт-Иске Писмән мәдәният йорты адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә; Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Писмән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе                                        Н.В.Дементьев